Яңа Кырлай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе

07 июнь 2019, Яңа Кырлай авылы, 14: 00 мин.

Үткәрү урыны: Яңа Кырлай авылы, мәдәният йорты

Чарада авыл җирлеге башлыгы Сәфәров Г. Г., Башкарма комитет секретаре Гыйззаэтуллина Г. Н., баш хисапчы Заһидуллина Ч. М. катнаштылар.

Барлыгы 10 кеше.

Сәфәров Г.Г.: Хәерле көн, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 26 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә бездә бүген Яңа Кырлай авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрелә.

Гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп җирлек башлыгы Сәфәров Г.Г. билгеләнде.

Секретаре: Гыйззэтуллина Г. Н. — авыл җирлекләренең хокук мәсьәләләре буенча белгече.

Яңа Кырлай авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-34 статьялары, «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә башланды.

Гавами тыңлауларның датасы турында мәгълүмат һәм кагыйдәләр, карарлар проекты Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, авыл җирлегенең торак пунктлары стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган иде:

Яңа Кырлай авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 нче йорт адресы буенча үткәрелә. Гавами тыңлаулар башланганчы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегеннән ПЗЗ проекты буенча язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кермәде. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегеннән ПЗ проекты буенча язмача һәм телдән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү сроклары 2018 елның 6 апреленнән 06 июненә кадәр. Шулай ук бернинди кисәтүләр һәм тәкъдимнәр дә булмады.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру максатларында эшләнә, шәһәр төзелешен зоналаштыруга керә. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү яңа Генераль планны раслау, РФ Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре түбәндәгеләрне үз эченә ала: аларны куллану һәм әлеге кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе; шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы; шәһәр төзелеше регламентлары.

Гыйззәтуллина Г. Н.: сораулар бармы? Гавами тыңлаулар уздыру барышында кисәтүләр булмады, кергән тәкъдим игътибарга алыначак. Әгәр сораулар юк икән, тыңлаулар гамәлдә булып санала.

Гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы Сәфәров Г.Г.

Секретаре: Гыйззәтуллина Г.Н.